**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ НЫРСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**
**Бишенче чакырылышның чираттан тыш утырышы**

**29.12.2025 ел** **№ 8** **Олы Нырсы ав.**

Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге Советының 15.11.2023 ел №95 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге Советының 15.11.2023 ел №95 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (01.11.2024 № 116 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктның 2.1 пунктчасын «, билгеләнешен проектлаучы күпфатирлы йорт булган төгәлләнмәгән төзелеш объектларыннан тыш» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Теләче муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга: http://tulachi.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
ОлыНырсы авыл җирлеге башлыгы Р.М.Гиниятов